| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Старокакерлинского**<br>**сельского поселения**<br>**Дрожжановского муниципального**<br>**района Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Чүпрәле муниципаль районы**<br>**Иске Кәкерле**<br>**авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**422476, Россия, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с. Старые Какерли, ул. Советская, д.51**
**тел. (84375) 30-1-35, 30-2-35, факс. 30-2-35**

Постановление Боерык
2023елның 18 сентябреннән №14

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Иске Кәкерле авыл җирлеге
җирле үзидарә органнары муниципаль
хезмәткәренең коррупциягә каршы
тәртибе стандартына үзгәреш кертү турында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге башлыгының 12.12.2017 елның 13 № - лы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы тәртибе стандартына (05.06.2018 елның 10 № - лы редакциясендә, 22.10.2018 елның 21 № - лы редакциясендә) түбәндәгеләрне кертергә: үзгәртү:

3.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (тормыш иптәшенең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәү, әгәр мондый мәгълүматларны тапшыру мәҗбүри булса, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган мәгълүмат бирү яки дөрес булмаган мәгълүматлар муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Кәкерле Районы Башлыгы
авыл җирлеге Фәтхуллин Р. Ф.